# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Алексеевск муниципаль районының Урта Тигәнәле авыл җирлегенең Түбән Тигәнәле авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча

21 декабрь 2021 е. № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Урта Тигәнәле авыл җирлеге составына керүче Түбән Тигәнәле авылы торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2022 елда Алексеевск муниципаль районының Урта Тигәнәле авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 1500 сум күләмендә үзара салым кертергә, моңа 1 төркем инвалидлар, студентлар, Россия Армиясе сафларына ашыгыч хезмәткә чакырылган гражданнар керми, һәм түбәндәге эшләрне үтәү буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү:

- җирлек эчендәге юлларны төзекләндерү һәм ремонтлау;
- җирлек эчендә юллар төзү;
- җирлек эчендәге юлларны кышкы һәм җәйге чорда карап тоту;
- Бөек Ватан сугышында һәлак булган сугышчыларга һәйкәл төзү;
- җирләү урыннарын төзекләндерү;
- су белән тәэмин итү системасын ремонтлау һәм аңа хезмәт күрсәтү

2. Әлеге карарны Урта Тигәнәле авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Урта Тигәнәле авыл җирлеге Советы бинасында мәгълүмат стендында урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Алексеевск муниципаль районының
Урта Тигәнәле авыл җирлеге башлыгы И.К.Хәмәтвәлиев